Республика Татарстан
СОВЕТ КАВЗИЯКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д. 66в, д.Кавзияково
423377
Телефон: 4-47-16

Татарстан Республикасы
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЭУЖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кәүҗияк авылы, Совет урамы, 66в
йорты, 423377
Телефон: 4-47-16

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 26 » ноябрь 2021 ел № 15

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» 2020 елның 18 маендагы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242_17 статьясындагы 4 пунктның гамәлдә булуын туктатып тору турында» 01.07.20021 ел, №244-ФЗ Федераль законның 1 статьясы нигезендә Кәүҗияк авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Советның 18.05.202020 ел, № 6 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 5 статьяның 9 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
6) "дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртип нигезендә, дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында Дәүләт Мәгълүмат Системасына физик һәм юридик затлар тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганагы булган башка түләүләрне түләү өчен кирәкле мәгълүматны, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, бирә.;
2) 5 статьяның 10 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
(3 пункт 2013 елның 16 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы редакциясендә) 3) җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын каплау өчен бүлеп бирелгән ассигнованиеләрне, бюджетның бердәм счетындагы калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә;;
3) 5 статьяның 11 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
- 2) җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының бюджетка керүенең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;;

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" урнаштырырга .PRAVO.TATARSTAN.RU) «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: https://sarmanovo.tatarstan.ru к

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф. Ә. Хөснетдинов